**Выступление** председателя Исполкома Всемирного конгресса татар **Р.З. Закирова** (на татарском языке)

Хөрмәтле Рөстәм Нургали улы! Хөрмәтле Минтимер Шәрип улы! Хөрмәтле утырышта катнашучылар!

Миңа, Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе буларак, халкыбыз тормышын, аның сулышын якыннан тоеп яшәргә туры килә. Урыннарда 400гә якын оешмалары булган Халыкара берләшмәнең илебез тормышында үз урыны бар. Конгресс күтәргән һәр мәсьәләне халык ихтыяҗы һәм аның гозере дип кабул итәргә кирәк. Кеше иркен сулаганда, нәрсә сулаганын, ничек сулаганын уйлап та тормый, ул аны шулай тиеш дип кабул итә. Ә инде кешенең тыны кысыла башлаганда, ул аның сәбәпләрен эзләргә керешә. Милләтара мөнәсәбәтләрне мин сулый торган һава белән чагыштырыр идем. Бу өлкәдә тәртип булганда, җәмгыять тә үзен иркен хис итә.

Ә хәзер конкрет мәсьәләләргә күчәм. Без күреп торабыз, Татарстан җитәкчелеге республикада яшәүче һәр милләт вәкилләренә мәдәниятләрен сакларга, милли ихтыяҗларын канәгатьләндерергә зур мөмкинлекләр бирә. Без моны үзебезнең Конгресс тормышында да һәрдаим тоеп торабыз. Соңгы елларда гына да татар халкы тормышына кагылган зур проектлар тормышка ашырыла. Әлеге эшләрнең берсен дә, Татарстан җитәкчелегенең ярдәмен, теләктәшлеген һәрдаим тоеп тормасак, башкарып чыгып булмас иде. Бу урында тагын бер әйбер турында аерым әйтергә кирәк. Татарстан Республикасы тарафыннан дәүләт дәрәҗәсендә кабул ителгән “Татар халкының милли үзенчәлекләрен саклау программасы” безне аеруча рухландырды. Чөнки аның нигезләре Бөтендөнья татар конгрессының V съездында кабул ителгән иде. Әлбәттә, бу Татарстан җитәкчелегенең җәмәгать оешмаларының тәкъдимнәренә дикъкать белән карауларын тасвирлый. Ул нәкъ кирәк вакытта кабул ителде һәм безгә киләчәккә өмет белән карарга мөмкинлек бирә. Бу тарихта беренче тапкыр турыдан-туры татар мәнфәгатьләрен кайгыртып эшләнгән җитди документ.

Чит җирләрдә яшәгән меңләгән милләттәшләребез Татарстанга һәм аның җитәкчелегенә бик рәхмәтле, шуңа да алар республикага һәрвакыт теләктәшлек күрсәтеп торалар. Ә бу илдә бик мөһим булган татар факторы дигән сүз.

Әле кайчан гына татар дин әһелләре арасында бердәмлек хыял гына булып тора иде. Һәм бу милли тормышка да, дини тормышка да зур зыян салып килде. Әлеге мәсьәләне җайга салу максатыннан Бөтендөнья татар конгрессы илнең татар дин әһелләрен Казанга җыю тәкъдиме белән чыккан иде. Татарстан Президенты бу эшкә үзенең фатихасын бирде. Бу аңлашыла да, чөнки Татар

конгрессын һәр татар кешесе милләтебезнең уртак мәйданы итеп кабул итә. Шуңа да татар дин әһелләре, конгресс ярдәме белән Казанга җыелып, уртак тел таба алдылар. Бу игелекле эш инде дистә елдан артык бара.

Кешеләрнең рухи халәте бик нечкә әйбер, монда аз гына гаделсезлек китсә дә, җәмгыятьнең тотрыклылыгы шунда ук үзгәрергә мөмкин. Бер генә мисал. Былтыр Татарстан өчен радиодулкыннар ешлыкларын бүлгәндә, Махсус федераль комиссия зур гаделсезлек җибәрде. Татарстанда 27 радиостанциясенең икесе генә татар телендә эшләп килүенә карамастан, яңа 2 ешлыкны да рус телле радиостанцияләргә бирделәр һәм шуның белән киң татар җәмәгатьчелегендә көчле ризасызлык тудырдылар. Бу мәсьәләдә Бөтендөнья татар конгрессы хәтта махсус белдерү белән чыгарга мәҗбүр булды. Ә бит халыкта зур шау-шу куптарган бу мәсьәләне җиңел генә гадел дә хәл итеп тә булыр иде. Ике ешлыкның берсен рус телле, икенчесен татар телле радиостанцияләргә биргәндә, барысы да канәгать булыр иде, минемчә. Андый комиссияләрдә, гадәттә, Татарстан вәкилләре дә катнаша, шуңа да без анда катнашкан вәкилләрнең татар халкының, республиканың милли мәнфәгатьләрен яклауларын да теләр идек.

Бөтендөнья татар конгрессына бик күп мәсьәләләр белән шөгыльләнергә туры килә, шулар арасында мәгариф өлкәсенә кагылганнары бигрәк тә кискен тора. Шул ук татар телендә укыту мәсьәләсен генә алыйк, бүген бу өлкә упкынга таба тәгәри дип әйтергә тулы нигез бар. Инде татар телендә фәннәрне укыту турында әйтәсе дә юк, хәтта татар телен укытырга белгечләр табып булмый. Чит төбәкләр турында әйтеп тормыйм, хәтта Татарстанда, Казанда да мондый белгечләрне “көндез чыра яндырып эзләргә” туры килә.

Татар теле Татарстанда инде 25 ел закон нигезендә дәүләт теле статусына ия. Шушы гомер эчендә аның һәр тармак өчен тиешле нормативлары эшләнмәгән. Урта мәктәптә татар телен укыту ниндидер бер мәгънәсез чара белән генә тәмамлана. Шуңа күрә татар теленә мөнәсәбәт балаларда да, ата-аналарда да тиешле дәрәҗәдә түгел. Ә бит уку елы дәвамында 9 нчы сыйныфка кадәр татар телен атнага 6 сәгать рус теле белән бер күләмдә укыталар. Дәүләт акчасын шулай сарыф итеп, бу эшне ниндидер уен белән тәмамларга ярыймы? Узган ел министрлык формаль рәвештә 9 нчы сыйныфта татар теленнән имтихан кертте кертүен, әмма күп кенә татар теле укытучылары бу мәсьәләдә канәгатьсезлек белдерә. Чөнки әлеге чара имтихан рәвешендә түгел, ә ниндидер бер “ачык дәрес” сыйфатында гына узган. Ә бит мондый имтихан нәтиҗәсендә балаларның кулларына дәүләт сертификаты бирсәк, ул аларга киләчәк тормышларында җитди документ булып тора алыр иде. Әйтик, дәүләт һәм муниципаль хезмәткә эшкә кергәндә, ул кешенең дәүләт теле буенча һөнәри күрсәткече булып торыр иде.

Министрлык бу идеяны инде 2 ел элек телдән хуплады, ләкин әлегә хәтле конкрет эшләр генә күренми.

Инде 3 ел элек Татарстан башкаласында республика күләмендәге татар интернат-гимназиясен ачу турында карар кабул ителгән иде. Шушы гомер эчендә бу мәсьәләдә бернинди алга китеш юк. Ә бит Казанда соңгы елларда нинди генә уку йортлары ачылмады, биналары да төзелде. Нишләп соң гомумреспублика татар гимназиясе проекты гына шундый мескен хәлдә? Нишләп соң без үзебезне шулай хөрмәт итмибез? Әлегә бу сорауларга җавап юк.

Гомумән, Татарстан Республикасында милләтара мөнәсәбәтләр төп халык булган татар милләтенең үз-үзен хис итүенә турыдан-туры бәйле. Без моның шулай икәнен үзебезнең эшчәнлегебез аркылы һәрдаим күреп торабыз. Әйе, мәктәпләрдә туган телдә укыту бик мөһим нәрсә, ә бит әле кешенең рухи тормышы да бар. Шуңа да татар дөньясының башкаласы Казанда без милли мохитнең үсүен теләр идек. Бөтен дөньядан бирегә татар мәркәзенең милли йөзен күрү максаты белән килгән кунакларга, аларның бу өметләрен аклар өчен, безгә әле бик нык тырышырга кирәк. Гомумән, милли мәсьәләләрне тиешле дәрәҗәдә хәл итеп бару җиңел эш түгел. Барыбызга бу эшләрдә уңышлар телим.

Рәхмәт.